# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 11

ноябрь
1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 11*

*ноябрь*

*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы №4304
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

Эчтәлек

# I

737.«Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 6

738.«Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 11

739.«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 28

740.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 31

741«.Татарстан Республикасы Югары суды Рәисен, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең беренче урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзаларын раслау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .... 33

742.«Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясын сайлау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 34

743.«2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 35

744.«Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 35

745.«Искергән торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 36

746.«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 36

747.«Коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 37

748.«2000-2005 елларда йогышлы авыруларны вакцина ярдәмендә профилактикалау» республика максатчыл программасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 37

749.«Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының эш урынындагы окладлары күләмен арттыру турында» *Татарстан*

*Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 38

750.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенең 1995 елның мартыннан алып 1999 елның октябрендә кадәр чордагы эше турында мәгълүмат хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 38

751.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы бәйләнеш мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турындагы хисап хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 39

752.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 39

753.«И.Г.Тарханов кандидатурасын Татарстан Республикасының мәдәният министры урынына килештерү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 40

754.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты проекты буенча җыелма бәяләмәсе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 40

**II**

755.«Татарстан Республикасы Президентының 2000 елга бюджет юлламасы буенча парламент тыңлаулары уздыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 42

756.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен чакыру вакытын үзгәртү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 42

757.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 43

758.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 44

759.«Татарстан Республикасының үсеш бюджеты турында" һәм "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законнары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 45

760.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясе чираттагы утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 46

761.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе эшен дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ... 46

762.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............................. 46
763.«1999 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............................................ 47
764.«1999 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............................................................ 49

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 737. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1994, № 12; Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 1995, № 12) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә - җирле үзенчәлекләрне һәм традицияләрне исәпкә алып, халыкның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне турыдан-туры яисә җирле үзидарә органнары аша хәл итүе буенча Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнүче мөстәкыйль һәм үз җаваплылыгындагы эшчәнлеге ул.»;

2 өлешне төшереп калдырырга;

3 өлешне 2 өлеш дип санарга.

2. 2 статьяда:

1 өлештә «башка» сүзе алдыннан «территориясендә гамәлдәге» дигән сүзләрне өстәргә.

3. 3 статьяда:

5 өлештә:

җиденче абзацта: «органнарының» сүзеннән соң «һәм урындагы затларының» дигән сүзләрне өстәргә;

унберенче, уникенче абзацларны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектә унберенче яңа абзац өстәргә:

«җирле үзидарәне гамәлгә ашыруның икътисадый һәм финанс нигезе, җирле үзидарә милкен биләүнең, аннан файдалануның һәм аның белән эш итүнең гомуми тәртибе;»;

унөченче-унбишенче абзацларны уникенче-ундүртенче абзацлар дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә яңа 6 өлеш өстәргә:

«6. Җирле үзидарә уставы рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә. Уставны басылып чыгару (халыкка игълан итү) тәртибен халык мөстәкыйль билгели.».

8 статьяда:

3 өлештә «шәхси» сүзе алдыннан «җирле үзидарә органнарының урындагы затларына» дигән сүзләрне өстәргә;

4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең урындагы затлары, әгәр законда башкасы каралмаган булса, һәркемгә аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында гражданнар тарафыннан бүтән төрле тулы һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиешләр.».

9 статьяда:

1 өлештә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә мәсьәләләре буенча законнар кабул итү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору»;

өченче абзацтан соң түбәндәге редакциядә яңа абзацлар өстәргә:

«бюджеттан минималь тәэмин итү нормативлары нигезендә җирле минималь бюджетларның нисбәтлелеген тәэмин итү;

җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда гражданнарның хокукларын яклау;

җирле үзидарәнең финанс мөстәкыйльлеге гарантияләрен тәэмин итү;

дәүләтнең социаль минималь стандартлары белән тәэмин итү;

җирле үзидарәләрне оештыру, үзгәртеп кору яисә бетерү тәртибен билгеләү һәм үзгәртү, аларның чикләрен һәм исемнәрен билгеләү һәм үзгәртү.»;

2 өлештә «законнары» сүзен «законы» сүзе белән алыштырырга.

12 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнарына дәүләтнең кайбер вәкаләтләре бирелергә мөмкин. Җирле үзидарә органнарына дәүләтнең кайбер вәкаләтләрен бирү, бер үк вакытта тиешле матди һәм финанс чараларын тапшырган килеш, закон белән гамәлгә ашырыла.».

14 статьяда:

1 өлешенең 2 абзацында «вакыты» сүзе алдыннан «күләме» сүзен өстәргә.

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының җирле үзидарә органнарына өстәмә чыгымнар китерерлек карарларын җирле үзидарә органнары үзләренә компенсация рәвешендә тапшырылган чаралар чикләрендә гамәлгә ашыралар.».

8. 16 статьяны төшереп калдырырга.

9. Законга түбәндәге эчтәлектә $19^1$ статья өстәргә:

«$19^1$ статья. **Территория иҗтимагый үзидарәсе**

1. Гражданнарның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча үз инициативаларын халыкның турыдан-туры хәл итүе аша яисә территория иҗтимагый үзидарәсенең үзләре төзегән органнары аша мөстәкыйль һәм үз җаваплылыгында гамәлгә ашырулары өчен яшәү урыны буенча җирле үзидарә территориясенең бер өлешендә оешулары территория иҗтимагый үзидарәсе була. Җирле үзидарә уставы нигезендә күрсәтелгән органнар юридик затлар булырга мөмкин.

2. Территория иҗтимагый үзидарәсен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы законнары аша һәм җирле үзидарә органнары актлары белән билгеләнә.».

10. 24 статьяга түбәндәге эчтәлектә 4 өлеш өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнарының вазыйфаи урыннарында эшләү вакыты дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә ташламалар һәм гарантияләр бирү өчен исәпләнә торган стажга кертелә.».

11. 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең икътисадый нигезен җирле үзидарә милке, җирле бюджет акчалары, бюджеттан тыш җирле фондларның, җирле валюта фондларының акчалары, дәүләтнең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарәгә тапшырылган дәүләт милке, шулай ук җирле үзидарә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен хезмәт итә торган бүтән милек тәшкил итә.».

28 статьяда:

4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары җирле үзидарә милкенә идарә итәләр. Җирле үзидарә милке составына керүче мөлкәткә карата милекчелек хокукларын җирле үзидарә исеменнән җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыралар, ә законнарда һәм җирле үзидарә уставларында каралган очракларда турыдан-туры халык үзе башкара.»;

6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җирле үзидарә милкен хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын Татарстан Республикасы законы нигезендә мөстәкыйль рәвештә турыдан-туры халык үзе яисә җирле үзидарә вәкиллекле вәкаләтләр тапшырган сайланулы органнар билгели.».

29 статьяда

1 өлештә «ресурслары» сүзен «чаралары» дип алмаштырырга;

2 өлештә:

«Татарстан Республикасы законнары нигезендә» дигән сүзләрне «законнар нигезендә» дигән сүзләргә үзгәртергә;

«түләүләрне» сүзеннән соң «шулай ук аларны түләү буенча ташламаларны» дигән сүзләр өстәргә;

3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен закон нигезендә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар төзергә, аларны үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итәргә хокуклы.».

14. Законга түбәндәге эчтәлектә 29[1] статья өстәргә:

«29[1] статья. **Җирле үзидарә органнарының җирле үзидарә милкендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Җирле үзидарә органнары закон нигезендә җирле үзидарә милкендәге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшчәнлеге максатларын, шартларын һәм тәртибен билгелиләр, аларның продукциясенә (хезмәт күрсәтүләренә) бәяләрне һәм тарифларны җайга салалар, аларның уставларын раслыйлар, әлеге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләрен билгеләп куялар һәм эштән азат итәләр, аларның эшчәнлеге турында хисаплар тыңлыйлар.

2. Җирле үзидарә органнары белән җирле үзидарә милкендәге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре арасындагы мөнәсәбәтләр хезмәт турындагы законнар нигезендә корыла.».

30 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнары җирле бюджетны мөстәкыйль рәвештә төзиләр, раслыйлар һәм үтиләр, шулай ук аның үтәлешен тикшереп торалар. Җирле үзидарә бюджетны җайга салу барышында барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан акча алу хокукына законнар нигезендә ия.»;

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле бюджетларның керем өлеше үз керемнәреннән һәм җайга салынучы керемнәрдән кертелүче кертемнәрдән, дәүләтнең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелүче финанс чараларыннан, төрле рәвешләрдәге финанс ярдәменнән, шул исәптән дотациядән, субвенциядән һәм башкалардан тора.

Җирле бюджет законнарда билгеләнгән акча чыганакларыннан, шулай ук законнарга каршы килми торган башка төрле акча чыганакларыннан төзелә.

Җирле бюджетларның үз керемнәренә җирле салымнар һәм җыемнар, җирле бюджетларның бүтән төрле үз керемнәре, федераль, республика салымнарының җирле бюджетларга даими нигездә беркетелгән өлешләре керә.

Җирле бюджетларның үз керемнәренә законнарда билгеләнгән башка түләүләр дә кертелергә мөмкин.

Әлеге түләүләр турыдан-туры җирле бюджетка кертелә.»;

3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле бюджетларның керемнәр һәм чыгымнар өлешләрендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләтнең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен финанслау аерым рәвештә карала.».

16. 31 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31 статья. **Минималь җирле бюджетлар тәэмин итү**

1. Дәүләт хакимияте органнары җирле бюджетларның кирәкле минималь чыгымнарын каплау өчен керем чыганакларын беркетү юлы белән җирле үзидарә органнарын минималь җирле бюджетлар белән законнар нигезендә тәэмин итәләр.

2. Җирле бюджетларның минималь кирәкле чыгымнары бюджеттан минималь тәэмин ителеш нормативлары нигезендә закон белән билгеләнә.

3. Минималь җирле бюджетларның керем өлеше керем чыганакларын закон нигезендә озак вакытка беркетү юлы белән тәэмин ителә. Әгәр минималь җирле бюджетның керем өлешен күрсәтелгән керем чыганаклары исәбеннән тәэмин итеп булмаса, дәүләт хакимияте органнары җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан бүтән төрле керем чыганаклары тапшыралар, бу чакта җирле бюджетларның узган елгы ирекле күчүче калдыклары исәп-хисапка алынмый.

4. Җирле үзидарә органнары җирле үзидарә карамагына кертелгән өлкәләрдә халыкның төп тормыш ихтыяҗларын дәүләтнең минималь социаль стандартларыннан да ким булмаган дәрәҗәдә канәгатьләндерүне тәэмин итәләр, аларны үтәү дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле бюджетларның керемнәренә законнар нигезендә салымнардан түләүләрне беркетү юлы белән дәүләт тарафыннан гарантияләнә.».

17. IV бүлеккә түбәндәге эчтәлектә $33^1$ статья өстәргә:

«$33^1$ статья. **Җирле үзидарә оганнарының табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләрне алу хокукы**

Җирле үзидарә органнары җирле үзидарә территориясендә чыгарыла торган табигый байлыклардан файдаланучылардан Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләү, шул исәптән натуралата түләү алалар.».

18. Законга түбәндәге эчтәлектә VII бүлек өстәргә:

### «VII БҮЛЕК. ЙОМГАК НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

41 статья. **Җирле үзидарә хезмәткәрләре турында**

Дәүләт хезмәткәрләре өчен Татарстан Республикасы

законнарында билгеләнгән гарантияләр тиешле закон кабул ителгәнче җирле үзидарә хезмәткәрләренә дә кагыла.».

2 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2390

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 738. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында

Әлеге Закон атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм гражданнарның сәламәт әйләнә-тирә табигать мохитенә конституциячел хокукын тәэмин итүгә юнәлтелгән.

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

атмосфера һавасы - әйләнә-тирә табигать мохитенең тормыш өчен мөһим компоненты, ул торак, җитештерү биналарының һәм башка биналарның тышындагы атмосфера газларының табигый катышмасыннан гыйбарәт;

атмосфера һавасын пычрату - атмосфера һавасына зарарлы химик, физик, биологик һәм башка йогынтылар ясау, моңа атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бөркелү яисә атмосфера һавасына аларның башка ысул белән чыгарылуы, яисә анда пычраткыч матдәләр, тавышлар, вибрацияләр, магнит кырлары барлыкка китерү һәм атмосфера һавасына бүтән зарарлы физик йогынтылар ясау да, шулай ук атмосфера һавасын аның торышын үзгәртелерлек итеп җитештерү ихтыяҗларында куллану да керә;

пычраткыч матдә - тузан, газсыман зарарлы матдәләр, билгеле бер концентрацияләрдә кеше сәламәтлегенә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына, әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынты ясарлык яисә атмосфера һавасыннан һәм әйләнә-тирә табигать мохитеннән файдалануның башка төрләренә тоткарлыклар тудыра торган химик, биологик һәм бүтән чыгышлы башка матдәләр, катышмалар һәм микроорганизмнар ул;

атмосфера һавасын пычратучы чыганаклар - атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бүлеп чыгара торган яисә зарарлы физик йогынтылар ясый торган хуҗалык объектлары һәм башка төрле объектлар, чаралар һәм җайланмалар ул;

атмосфера һавасын чиктәш пычрату - атмосфера һавасын чыганагы Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан килеш пычрату ул;

атмосфера һавасын саклау - атмосфера һавасын чиста килеш саклап калуга һәм атмосфера һавасының торышын яхшыртуга, аның пычрануын булдырмый калуга, киметүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән эшчәнлек ул;

атмосфера һавасының дәүләт мониторингы - атмосфера һавасының торышын һәм аны пычрату чыганакларын даими күзәтү, хуҗалык һәм башка эшчәнлек, метеорологик шартлар йогынтысында атмосфера һавасы торышын үзгәртүнең төп тенденцияләрен бәяләү һәм фаразлау системасы ул;

һәлакәт вакытында пычраткыч матдәләр бөркелү - технология процессы шартларын бозу яисә һәлакәтләр нәтиҗәсендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бүлеп чыгару ул;

берьюлы бик күп пычраткыч матдәләр бөркелү - кыска гына вакыт эчендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрне уртача дәрәҗәдән ике тапкырдан да артыграк бөркелеп чыгару;

бөркелүнең техник нормативы - атмосфера һавасына пычраткыч матдә бөркелүнең заманча техник казанышлар нигезендә җиһазларның һәм җайланмаларның технологик процесслары өчен билгеләнүче һәм, продукциянең, куәтләрнең берәмлегенә, транспорт яисә башка төрле йөрү чараларының юл үтү берәмлегенә карата исәпләгәндә, атмосфера һавасына пычраткыч матдә бөркелүнең иң чик мөмкин массасын чагылдыручы норматив яисә башка күрсәткечләре ул;

пычратуның мәйдан чыганагы - бик зур территория биләүче оештырылмаган чыганак яисә атмосфера һавасын пычратуның берән-сәрән чыганакларының берлеге ул (парга әйләнүче буалар, шлак туплаучылар, терриконнар, ишелеп төшүләр, чүплекләр һәм пычратуның башка чыганаклары).

**2 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләр әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының аның нигезендә кабул ителүче бүтән норматив-хокукый актлары белән җайга салыналар.

**3 статья. Атмосфера һавасын саклауның һәм аннан нәтиҗәле файдалануның төп принциплары**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану түбәндәге төп принциплар нигезендә башкарыла:

законлылык;

гражданнарның сәламәт әйләнә-тирә табигать мохитенә

хокукларын тәэмин итүнең өстенлеге;
түләүле булу;
халыкара хезмәттәшлек.

## II бүлек. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының компетенциясе

### 4 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясе

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне закон чыгару юлы белән җайга салу;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә республиканың иң мөһим программаларын раслау;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан файдалану өлкәсендәге законнарның үтәлешен контрольдә тоту.

### 5 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясе

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары эшчәнлегенә үз вәкаләтләре чикләрендә юнәлеш бирү;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә республиканың мөһим программаларын әзерләү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кертү;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә республика һәм федераль программаларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

атмосфера һавасын пычраткан өчен түләүләрне исәпләп чыгару һәм түләттерү тәртибен билгеләү;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану

өлкәсендә законнарда каралган башка төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**6 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы компетенциясе**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашырырга Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан вәкаләтләр тапшырылган дәүләт идарәсенең республика органы атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы була.

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә бердәм фәнни-техник сәясәт уздыру;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының эшчәнлегенә җитәкчелек итү;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт программаларын әзерләүдә катнашу;

гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы белән берлектә, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарын, җирле үзидарә органнарын һәм башка кызыксынучы затларны атмосфера һавасының торышы турындагы мәгълүмат белән тәэмин итү;

атмосфера һавасын пычратуның дәүләт исәбен һәм атмосфера һавасы мониторингын гамәлгә ашыру;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру;

законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**7 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә халык депутатларының җирле Советлары компетенциясе**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә халык депутатларының җирле Советлары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә программаларны үз вәкаләтләре чикләрендә карау һәм раслау;

атмосфера һавасын саклауга һәм аннан нәтиҗәле файдалануга юнәлдерелгән чаралар белән тәэмин итү;

индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның атмосфера

һавасын саклауга һәм аннан нәтиҗәле файдалануга юнәлдерелгән эшчәнлеген үз вәкаләтләре чикләрендә икътисадый кызыксындыру;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә законда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**8 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә район, шәһәр, шәһәрдәге район җирле администрациясе компетенциясе**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә район, шәһәр, шәһәрдәге район җирле администрациясе компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану буенча үз вәкаләтләре чикләрендә проектлар әзерләү һәм программаларны гамәлгә ашыру;

үз территориясендә яшәүче халыкка атмосфера һавасының торышы турындагы мәгълүматны җиткерү;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә законда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**9 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясе**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

җирле үзидарә территориясен яшелләндерү;

көнкүреш калдыкларын җыюны һәм читкә чыгаруны оештыру;

законнарда каралган башка төрле вәкаләтләрне, шулай ук үзләренә билгеләнгән тәртиптә тапшырылган кайбер дәүләти вәкаләтләрне башкару.

## III БҮЛЕК. АТМОСФЕРА ҺАВАСЫН САКЛАУНЫ ҺӘМ АННАН НӘТИҖӘЛЕ ФАЙДАЛАНУНЫ ИКЪТИСАДЫЙ ҖАЙГА САЛУ

**10 статья. Атмосфера һавасын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салу**

Атмосфера һавасын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салу түбәндәгеләрне күз алдында тота:

атмосфера һавасын пычраткан өчен түләү билгеләүне;

атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге эшчәнлекне икътисадый кызыксындыруны;

атмосфера һавасын пычрату лимитларын билгеләүне.

**11 статья. Атмосфера һавасын пычраткан өчен түләү**

Атмосфера һавасын пычраткан өчен түләү әйләнә-тирә табигать

мохитенә китерелгән зыянны компенсацияләүнең бер рәвеше булып тора.

Атмосфера һавасын пычраткан өчен түләү законнарда билгеләнгән тәртиптә алына.

Атмосфера һавасын пычраткан өчен түләү кертү индивидуаль эшкуарларны һәм юридик затларны атмосфера һавасын саклау гамәлләрен үтәүдән һәм атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозу нәтиҗәсендә китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

**12 статья. Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруга һәм атмосфера һавасына аерым төр зарарлы физик йогынтылар ясауга махсус рөхсәтләр (лицензияләр) биргән өчен җыем**

Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруга һәм атмосфера һавасына аерым төр зарарлы физик йогынтылар ясауга махсус рөхсәтләр (лицензияләр) биргән өчен җыем атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан алына.

Күрсәтелгән махсус рөхсәтләрне (лицензияләрне) биргән өчен җыем күләме, гаризалар буенча экспертизалар үткәрү өчен кирәкле чыгымнардан, махсус рөхсәтләр (лицензияләр) бирүгә бәйле оештыру чыгымнарыннан һәм башка төрле чыгымнардан чыгып, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.

**13 статья. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә икътисадый кызыксындыру**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге эшчәнлекне икътисадый кызыксындыру атмосфера һавасын саклауга юнәлдерелгән эшләрне башкаручы, атмосфера һавасын саклауны тәэмин итә торган фәнни-техник казанышларны гамәлгә кертүче, чистарткыч корылмалар, җиһазлар һәм тикшерүүлчәү приборлары җитештерүче, шулай ук, атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бөркелүне арттырмыйча гына, экологик чиста продукция җитештерүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга законнар нигезендә салым ташламалары һәм башка өстенлекле ташламалар бирү юлы белән тормышка ашырыла.

**14 статья. Атмосфера һавасын пычрату лимитлары**

Атмосфера һавасын пычрату лимитлары территорияләр буенча экологик чикләүләр системасы булалар һәм атмосферага пычраткыч матдәләр чыгаруның мәгълүм бер вакытка билгеләнгән иң чик мөмкин

күләмнәрен чагылдыралар.

Атмосфера һавасын пычрату лимитлары атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруга бәйле эшчәнлек белән шөгыльләнүче индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар өчен, республикадагы экологик вәзгыятьне исәпкә алып, билгеләнгән нормативлардан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган тәртиптә атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан билгеләнәләр.

## IV БҮЛЕК. АТМОСФЕРА ҺАВАСЫН САКЛАУ ҺӘМ АННАН НӘТИҖӘЛЕ ФАЙДАЛАНУ БУЕНЧА ТАЛӘПЛӘР

### 15 статья. Атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру шартлары

Индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның стационар чыганактан атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгара торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруы, шулай ук атмосфера һавасына аерым төр зарарлы физик йогынтылар ясавы атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан бирелүче махсус рөхсәт (лицензия) нигезендә генә рөхсәт ителә.

Махсус рөхсәттә (лицензиядә) атмосфера һавасын пычрату лимитлары, атмосфера һавасына чыгарыла торган зарарлы матдәләрнең һәм аңа булган зарарлы физик йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары, пычраткыч матдәләр бөркелүне киметү гамәлләре, лицензиядә күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү нәтиҗәләре, шулай ук атмосфера һавасын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итүче башка шартлар һәм таләпләр күрсәтеләләр.

Атмосфера һавасына зарарлы физик йогынтыларның махсус рөхсәтләр (лицензияләр) нигезендә генә ясалу ихтималы булган аерым төрләренең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.

### 16 статья. Атмосфера һавасының сыйфатын нормалаштыру

Атмосфера һавасының сыйфатын нормалаштыру йогынтыларның халыкның, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының, әйләнә-тирә табигать мохитенең экологик иминлеген гарантияләүче иң чик мөмкин нормаларын билгеләү максатында башкарыла.

Атмосфера һавасының торышын бәяләү өчен пычраткыч матдәләр концентрацияләренең һәм атмосфера һавасына зарарлы физик йогынты дәрәҗәләренең иң чик мөмкин нормативлары билгеләнә.

Пычраткыч матдәләр концентрацияләренең һәм атмосфера

һавасына зарарлы физик йогынты дәрәҗәләренең иң чик мөмкин нормативлары, аларны билгеләү алымнары законнарда билгеләнгән тәртиптә расланалар һәм гамәлгә кертеләләр. Махсус сакланылучы табигать территорияләре, курортларның санитар саклау зоналары, шәһәрләрнең, торак пунктларының ял зоналары өчен пычраткыч матдәләр концентрацияләренең һәм атмосфера һавасына зарарлы физик йогынты дәрәҗәләренең иң чик мөмкин катгыйрак нормативлары законнарда билгеләнгән тәртиптә билгеләнәләр.

### 17 статья. Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең һәм аңа зарарлы физик йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану максатларында стационар һәм күчерелмә пычрату чыганакларыннан пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең иң чик мөмкин нормативлары, шулай ук зарарлы физик йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары билгеләнә. Бу нормативлар һәр пычрату чыганагы буенча атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы һәм халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан билгеләнә.

Атмосферага пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең һәм аңа зарарлы физик йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары, пычрату чыганагы үз чикләрендә урнашкан торак пункты үсешенең перспективасын исәпкә алып, күрсәтелгән бөркелүләр һәм йогынтылар атмосфера һавасындагы пычраткыч матдәләр концентрацияләренең иң чик мөмкин нормативларын һәм зарарлы физик йогынтыларның иң чик мөмкин нормативларын арттыруга китермәслек дәрәҗәдә билгеләнәләр.

Атмосферага пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең һәм аңа зарарлы физик йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары, аларны билгеләү алымнары һәм нормативлар әзерләнә торган чыганакларның төрләре законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана һәм гамәлгә кертелә.

### 18 статья. Тиешле нормативлар булмаганда атмосфера һавасын пычратуны җайга салу

Тиешле нормативлар билгеләнмәгән килеш, атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлек атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы рөхсәте белән аерым очракларда гына һәм билгеле бер вакыт эчендә генә башкарылырга мөмкин, шул рөхсәтне биргәндә вакытлыча килештерелгән нормативлар расланалар.

Шушы вакыт эчендә тиешле норматив билгеләнергә һәм атмосфера һавасын саклау буенча кирәкле гамәлләр үткәрелергә тиеш.

**19 статья. Хуҗалык объектларын һәм башка төрле объектларны проектлаганда, урнаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда, файдалануга тапшырганда атмосфера һавасын саклау**

Хуҗалык объектларын һәм башка объектларны проектлаганда, урнаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда, файдалануга тапшырганда, шулай ук яңа технологик процессларны гамәлгә керткәндә атмосфера һавасының торышына аларның турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясаулары искә алынырга тиеш, зарарлы матдәләрне һәм калдыкларны тотып калу, файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру яисә пычраткыч матдәләрнең бөркелеп чыгуын бөтенләй булдырмау, җитештерү ихтыяҗлары өчен атмосфера һавасын минималь дәрәҗәдә куллануны тәэмин итүче чаралар күз алдында тотылырга тиеш, шулай ук атмосфера һавасын саклау буенча башка таләпләрне үтәү каралырга тиеш.

Атмосфера һавасын пычрата торган хуҗалык объектларын һәм башка төрле объектларны урнаштыру, төзү, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Түбәндәгеләрне файдалануга кертү тыела:

атмосфера һавасына чыгарып ташланучы пычраткыч матдәләрне чистарта торган корылмалар, җиһазлар һәм аппаратура белән һәм пычраткыч матдәләрнең микъдарын һәм составын тикшереп торучы чаралар белән җиһазландырылмаган хуҗалык объектларын һәм башка төрле объектларны;

санитар-яклау зоналары булмаган җитештерү комплексларын.

**20 статья. Хуҗалык объектларыннан һәм башка төрле объектлардан файдаланганда атмосфера һавасын саклау таләпләре**

Атмосфера һавасын пычратучы чыганаклары булган хуҗалык объектларыннан һәм башка төрле объектлардан файдаланучы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруга һәм аерым төр зарарлы физик йогынтылар ясауга махсус рөхсәттә (лицензиядә) каралган шартларны һәм таләпләрне үтәргә;

табигатьтән файдаланучы башка затларның хокукларын бозмаска, шулай ук кешеләр сәламәтлегенә, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китермәскә;

атмосфера һавасына чыгарып ташлана торган пычраткыч матдәләрне чистарту өчен билгеләнгән корылмаларның, җиһазларның, аппаратураның һәм чыгарылучы пычраткыч матдәләрнең микъдарын

һәм составын тикшереп тору чараларының өзлексез нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә һәм аларны төзек хәлдә тотарга;

санитар-яклау зоналарының билгеләнгән режимын үтәүне тәэмин итәргә;

әлеге Законны бозуны бетерү буенча әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органнарның законлы күрсәтмәләрен үтәргә;

атмосфера һавасына бөркелүләрнең стационар чыганакларын тикшереп тору чаралары белән җиһазлау рәвешендә атмосфера һавасына чыгарып ташланучы пычраткыч матдәләрнең микъдарын һәм составын даими исәпкә алуны гамәлгә ашырырга, шулай ук атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт статистика хисабын билгеләнгән тәртиптә биреп барырга;

атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрне бөркелүләрнең билгеләнгән нормативларын үтәүне законда билгеләнгән рәвештә оештырырга һәм житештерү күзлегеннән чыгып тикшереп торырга;

атмосфера һавасын пычраткан өчен вакытында түләргә;

атмосфера һавасы торышына йогынты ясарлык һәлакәт һәм башка гадәттән тыш вәзгыятьләр турында дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнарына, җирле үзидарә органнарына билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә;

атмосфера һавасы торышына йогынты ясарлык һәлакәт һәм башка гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләрне вакытында тормышка ашырырга;

атмосфера һавасын саклау буенча билгеләнгән башка таләпләрне һәм атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарда каралган бүтән бурычларны үтәргә.

Хуҗалык объектларыннан һәм башка төрле объектлардан файдаланганда түбәндәгеләр тыела:

атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруга һәм атмосфера һавасына аерым төр зарарлы физик йогынтылар ясауга махсус рөхсәт (лицензия) булмаган килеш, атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару;

билгеләнгән нормативлар нигезендә алдан чистартмыйча һәм зарарсызландырмыйча атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару;

йогышлы авырулар китереп чыгаручы пычраткыч матдәләрне, шулай ук пычраткыч матдәләр чыгаруның иң чик мөмкин нормативлары яисә вакытлыча килешенгән нормативлары билгеләнмәгән пычраткыч матдәләрне чыгару.

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану таләпләрен бозу атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлекне әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә чикләүгә, туктатып торуга яисә бөтенләй туктатуга китерә.

**21 статья. Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын проектлаганда, төзегәндә һәм үзгәртеп корганда атмосфера һавасын саклау**

Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын проектлаганда, төзегәндә һәм үзгәртеп корганда атмосфера һавасының торышы, аның үзгәрү фаразы һәм атмосфера һавасын пычранудан саклау буенча билгеләнгән таләпләр исәпкә алынырга тиеш.

Атмосфера һавасын пычратуны булдырмау яисә киметү максатында дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары - шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын проектлаганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда торак пунктлары территорияләрен, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар исә үзләре биләгән җитештерү мәйданнарын һәм башка төрле мәйданнарны төзекләндерүне һәм яшелләндерүне яхшырту чараларын күрергә тиеш.

**22 статья. Пычратуның хәрәкәтләнүчән чыганакларыннан пычраткыч матдәләр бөркелүләрдән атмосфера һавасын саклау**

Атмосфера һавасын пычрату чыганаклары булган автомобильләрне, самолетларны, судноларны, тепловозларны, авыл хуҗалыгы һәм юл төзелеше машиналарын һәм башка хәрәкәтләнүчән чараларны һәм җайланмаларны проектлаучы һәм җитештерүче гражданнар һәм юридик затлар шушы чаралардан һәм җайланмалардан атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрне чыгармый калу һәм киметү буенча чаралар комплексын әзерләргә һәм гамәлгә ашырырга тиеш, шул исәптән пычраткыч матдәләр бөркелүләрне киметүгә юнәлдерелгән яңа фәнни-техник казанышларны, шулай ук пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлауларның кимүен тәэмин итә торган двигатель көйләү чараларын һәм ысулларын, транспорт чараларында эшләнгән газларны нейтральләштерү системасын, мотор ягулыгының аз агулы төрләрен кулланырга тиеш.

Атмосфера һавасына чыгарып ташланучы пычраткыч матдәләре билгеләнгән нормативлардан артып китә торган, атмосфера һавасын пычрату чыганаклары булган автомобильләрне, самолетларны, судноларны, тепловозларны, авыл хуҗалыгы һәм юл төзелеше машиналарын һәм башка хәрәкәтләнү чараларын һәм җайланмаларын җитештерү һәм алардан файдалану рөхсәт ителми.

Атмосфера һавасын пычратучы файдаланудагы барлык хәрәкәтләнүчән чыганаклар пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең техник нормативларга туры килү-килмәүләренә даими тикшерү узарга тиеш. Атмосфера һавасын пычратучы хәрәкәтләнүчән чыганакларның хуҗалары күрсәтелгән тикшерүләрне узуны тәэмин итәргә тиеш.

Атмосфера һавасын саклау һәм махсус сакланылучы табигать территорияләренең режимын үтәү максатларында атмосфера һавасын

саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы һәм махсус вәкаләтле бүтән органнар Татарстан Республикасының дәүләт табигать тыюлыкларына һәм махсус сакланылучы бүтән территорияләренә транспорт һәм башка төрле хәрәкәтләнү чараларының, җайланмаларының үтеп йөрүләрен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртип нигезендә җайга салалар.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары транспорт һәм башка төрле хәрәкәтләнү чараларының, җайланмаларының торак пунктларына, аларның аерым районнарына, дәвалау-савыктыру урыннарына, курорт зоналарына, күмәкләп ял итү, туризм һәм спорт урыннарына үтеп керүләренә законнар нигезендә чикләүләр кертә алалар.

23 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдаланганда атмосфера һавасын саклау**

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнгәндә, разведкалаганда һәм файдалы казылмалар чыгарганда, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә һәм алардан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланучылар атмосфера һавасын пычратуны булдырмый калу һәм киметү чараларын күрергә тиеш.

24 статья. **Пычратуның мәйдан чыганакларыннан атмосфера һавасын саклау**

Атмосфера һавасын пычратуның мәйдан чыганакларын урнаштыру һәм алардан файдалану законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш башкарылырга тиеш.

Торак пунктларында пычратуның мәйдан чыганакларын урнаштыру, шулай ук күрсәтелгән предприятиеләр, оешмалар һәм торак пунктлары территориясендә җитештерү һәм куллану калдыкларын яндыру тыела, моңа, атмосфера һавасын саклау таләпләрен үтәгән килеш, махсус җайланмалар кулланып яндыру очраклары керми.

Хуҗалык эшчәнлекләре һәм башка төрле эшчәнлекләр нәтиҗәсендә атмосфера һавасын пычратучы калдыклар барлыкка китерә торган индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар калдыкларны файдалы эшкә тотучы предприятиеләргә һәм оешмаларга билгеләнгән тәртиптә яисә махсус саклау йә күмү урыннарына илтеп тапшыруны тәэмин итәргә тиешләр. Районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрдәге районнарның җирле администрацияләре, җирле үзидарә органнары тиешле территориядә барлыкка килгән көнкүреш калдыкларын җыюны һәм читкә чыгаруны оештыралар.

25 статья. **Химик матдәләр кулланганда атмосфера һавасын саклау**

Авыл хуҗалыгында, җитештерү эшчәнлегендә һәм бүтән төрле

эшчәнлектә химик матдәләрне куллану бары тик атмосфера һавасын нормативтан тыш пычратуга китермәгән очракта гына рөхсәт ителә.

Күрсәтелгән максатлар өчен кулланылучы яңа препаратлар барлыкка китергәндә концентрацияләрнең иң чик мөмкин нормативларын һәм атмосфера һавасында бу препаратларның калган өлешен билгеләү алымнары әзерләнергә тиеш.

Гражданнар һәм юридик затлар атмосфера һавасын пычратмас өчен химик матдәләрне авыл хуҗалыгында, житештерү эшчәнлегендә һәм бүтән эшчәнлектә транспортлау, саклау һәм куллану кагыйдәләрен, алардан файдалануның билгеләнгән нормативларын үтәргә тиешләр.

### 26 статья. Атмосфера һавасын зарарлы физик йогынтылардан саклау

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм гражданнар атмосфера һавасына булган шау-шуларны, вибрацияләрне, магнит кырларын, нурланышларны һәм башка төрле зарарлы физик йогынтыларны кисәтү, киметү һәм бетерү өчен кирәкле чараларны күрергә тиеш.

Көчле шау-шу һәм вибрация чыганагы булган сәнәгать җитештерүләрен, шулай ук җайланмаларын һәм җиһазларын торак йортларында урнаштыру тыела.

Гражданнар атмосфера һавасын торак биналардагы, шулай ук торак йортларның ишек алларындагы, урамнардагы, ял итү урыннарындагы һәм башка җәмәгать урыннарындагы көнкүреш шау-шуыннан саклау буенча дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән таләпләрне үтәргә тиешләр.

### 27 статья. Газ чистарту җайланмаларын эксплуатацияләүгә карата төп таләпләр

Индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар газ чистарту җайланмаларын төзек хәлдә тотуны, проектка туры килүче күрсәткечләр нигезендә аларның ышанычлы, өзлексез эшләүләрен тәэмин итәргә тиеш. Газ чистарту җайланмалары туктатылган килеш технологик җайланмалардан файдалану тыела.

Газ чистарту җайланмалары атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органында мәҗбүри теркәлергә тиеш.

### 28 статья. Уңайсыз метеорологик шартларда атмосфера һавасын саклау

Көтеләчәк уңайсыз метеорологик шартларга бәйле рәвештә атмосфера һавасында пычраткыч матдәләрнең концентрациясе арту мөмкинлеге турында кисәтү алганда, пычратуның стационар чыганаклары хуҗалары булган индивидуаль эшкуарлар һәм юридик

затлар, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, атмосфера һавасына чыгарылучы пычрак матдәләрне киметү буенча махсус әзерләнгән гамәлләрне башкарырга тиеш.

Күрсәтелгән кисәтүләр гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан җибәрелә.

29 статья. **Һәлакәт һәм башка төрле гадәттән тыш вәзгыять килеп чыкканда яисә атмосфера һавасы экстремаль югары дәрәҗәдә пычранганда аны саклау**

Һәлакәт һәм башка төрле гадәттән тыш вәзгыять нәтиҗәсендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең иң чик мөмкин нормативлары артып киткәндә, пычрату чыганакларының хуҗалары булган индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарына, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына, җирле үзидарә органнарына бу хакта кичекмәстән хәбәр итәргә һәм атмосфера һавасының пычрануы сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен бетерү чараларын билгеләнгән тәртиптә күрергә тиеш.

Атмосфера һавасы экстремаль югары дәрәҗәдә пычранганда дәүләт идарәсе органнары пычрану сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү гамәлләрен әзерлиләр һәм башкаралар.

Атмосфера һавасының торышына йогынты ясарлык һәлакәтләр һәм башка төрле гадәттән тыш вәзгыятьләр булганда яисә атмосфера һавасының экстремаль югары дәрәҗәдә пычрану очрагы килеп чыкканда, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарының үзара ярдәмләшү һәм мәгълүмат тапшырышу тәртибе, шулай ук аны билгеләү критерийлары законнар нигезендә билгеләнә.

Антропоген процесслар нәтиҗәсендә атмосфера һавасының торышында кире кайтарып алмаслык кискен үзгәрешләр барлыкка килгән кайбер территорияләр законда билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш экологик вәзгыять яисә экологик афәт зоналары дип игълан ителергә мөмкин.

30 статья. **Атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлекне чикләү, туктатып тору һәм тыю**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозганда, атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлек чикләнергә, туктатып торылырга яисә тыелырга мөмкин.

Атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлекне чикләү атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруга һәм атмосфера һавасына аерым төр зарарлы физик йогынтылар ясауга махсус

рөхсәттә (лицензиядә) каралган шартлар һәм таләпләр бозылган очракларда гына башкарыла.

Җитештерүләрне, цехларны, участокларны, җиһазларны файдалануны туктатып тору атмосфера һавасына пычрак матдәләрне нормативтан тыш чыгаруга китерүче технологик һәм башкача хокук бозулар очрагында, предприятиенең санитар-яклау зонасы чикләрендә бер яисә берничә матдәнең микъдары санитария-гигиена нормативларыннан артып киткәндә гамәлгә ашырыла.

Атмосфера һавасын экстремаль югары пычратуга китерүче һәм гражданнар сәламәтлегенә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян килү куркынычы барлыкка китерүче, шул исәптән атмосфера һавасын анық торышын үзгәртүгә китерерлек итеп җитештерү ихтыяҗларында куллану нәтиҗәсендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бөркелүләр тыелырга тиеш.

Атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлекне чикләү, туктатып тору һәм тыю турындагы карарларны атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә кабул итә.

## V бүлек. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм тикшереп торуы

**31 статья. Атмосфера һавасын пычратуны дәүләт исәбенә алу**

Атмосфера һавасын пычратучы стационар чыганаклар һәм хәрәкәтләнү чаралары, атмосфера һавасына чыгарып ташланучы пычраткыч матдәләрнең төрләре һәм микъдары, атмосфера һавасына зарарлы физик йогынтыларның төрләре һәм күләмнәре дәүләт исәбенә алынырга тиеш.

Атмосфера һавасын пычратуны дәүләт исәбенә алуны, статистика буенча махсус вәкаләтле дәүләт органы белән берлектә, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы гамәлгә ашыра.

Атмосфера һавасын пычратучы стационар чыганакларның хуҗалары булган индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар бу чыганакларны билгеләнгән тәртиптә барлап чыгарга тиеш.

**32 статья. Атмосфера һавасының дәүләт мониторингы**

Атмосфера һавасының дәүләт мониторингы, атмосфера һавасын саклау буенча карарлар кабул итү һәм гамәлләр башкару өчен тәкъдимнәрне әзерләү, шулай ук атмосфера һавасының пычрануы дәрәҗәләре турындагы агымдагы һәм экстерн мәгълүмат, атмосфера һавасының торышы турындагы фаразлар белән тәэмин итү өчен атмосфера һавасының дәүләт мониторингы гамәлгә ашырыла.

Атмосфера һавасының торышы һәм аны пычрату

чыганаклары турындагы мәгълүматны җыю, саклау, эшкәртү һәм тапшыру Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохите мониторингының бердәм системасы кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, шулай ук махсус вәкаләтле бүтән органнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

33 статья. **Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге программалар**

Атмосфера һавасының торышын саклап калу һәм аның сыйфатын яхшыртуны тәэмин итү буенча нәтиҗәле һәм максатчыл эшчәнлек оештыру өчен, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану гамәлләрен планлаштыру өчен атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә законнар нигезендә расланучы дәүләт программалары әзерләнә һәм гамәлгә ашырыла.

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану программаларын финанслау законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

34 статья. **Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт тикшереп торуы**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле бүтән органнар үз компетенцияләре чикләрендә гамәлгә ашыралар.

Пычратуның стационар чыганакларыннан пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең иң чик мөмкин нормативлары үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы башкара.

Хәрәкәттәге пычрату чыганакларыннан пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең иң чик мөмкин нормативлары үтәлешен дәүләт тикшереп торуын, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүче дәүләт органы белән берлектә, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы гамәлгә ашыра.

Стационар чыганаклардан һәм хәрәкәттәге пычрату чыганакларыннан атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бөркелүләрнең иң чик мөмкин нормативлары үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп торуның төп бурычы атмосфера һавасына

фактик бөркелүләрнең билгеләнгән нормативларга туры килү-килмәвен тикшерүдән гыйбарәт.

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

35 статья. **Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә җитештерү һәм җәмәгать тикшереп торуы**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә җитештерү һәм җәмәгать тикшереп торуы законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик затлар һәм гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## VI бүлек. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

36 статья. **Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителәләр.

## VII бүлек. Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

37 статья. **Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык**

Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозган өчен юридик затлар һәм гражданнар закон нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

Җаваплылыкка тарту гаепле затларны хокук бозуларны төзәтү һәм китерелгән зыянны түләү вазыйфаларыннан азат итми.

## VIII бүлек. Йомгак нигезләмәләр

38 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты өч ай вакыт эчендә:

үзенең норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга;

әлеге Законны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив-хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2442

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 739. Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында

Әлеге Закон торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм Татарстан Республикасы гражданнарының торакка конституциячел хокукын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

**1 статья. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме - торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак бинасы сатып алуда, төзүдә яисә аны реконструкцияләүдә дәүләт ярдәме.

яшь гаилә - законнар нигезендә теркәлгән никахтан соң баштагы өч елдагы гаилә (гаиләдә бала булган очракта - никахның дәвамлылыгына бәйсез рәвештә), ул гаиләдә ир белән хатынның берсе - 30 яшькә җитмәгән, ә балалы тулы булмаган гаиләләр өчен - ана яисә ата 30 яшькә җитмәгән булырга тиеш;

вәкаләтле дәүләт органы - дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органы.

**2 статья. Дәүләт ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Торак шартларын яхшыртканда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләр әлеге Закон һәм башка норматив хокукый актлар белән җайга салына.

**3 статья. Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәменең рәвешләре**

Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме кире кайтарулы, ташламалы, вакытлы нигезләрдә түбәндәге рәвешләрдә күрсәтелә:

- яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү;
- яшь гаиләнең торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүен тәэмин итү.

**4 статья. Дәүләт ярдәме күрсәтү өчен нигезләр**

Дәүләт ярдәме законнар нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә күрсәтелә.

**5 статья. Дәүләт ярдәме күрсәтү турында карар кабул итү тәртибе**

Дәүләт ярдәме алу өчен яшь гаилә яшәү (теркәлү) урыны буенча район, шәһәр яисә шәһәрдәге район җирле администрациясенә

тиешле гариза белән мөрәҗәгать итә. Гаризага кушылып бирелүче документлар исемлеге, аларны карау тәртибе, шулай ук яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Дәүләт ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителгәнче, район, шәһәр һәм шәһәрдәге район җирле администрациясе тарафыннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана торган Нигезләмә нигезендә эш итүче торак-көнкүреш комиссиясе яшь гаиләләрнең торак шартларын тикшерә.

Дәүләт ярдәме күрсәтү турындагы карар, дәүләт ярдәме күрсәтү өчен нигезләр булганда, район, шәһәр яисә шәһәрдәге район администрациясе тәкъдиме буенча, чират тәртибендә вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан кабул ителә. Карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә вәкаләтле дәүләт органы әлеге карар турында яшь гаиләгә хәбәр итә.

**6 статья. Дәүләт ярдәмен финанслау өчен бүлеп бирелүче финанс чараларының күләме**

Яшь гаиләгә дәүләт ярдәме күрсәтүне финанслау өчен бүлеп бирелүче финанс чараларының күләме хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясендә билгеләнгән 1500 минималь күләменнән артмаска тиеш.

Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган акчалар әлеге Закон нигезендә яшь гаиләләр белән төзелгән шартнамәләрне дәүләт теркәвенә алуга бәйле чыгымнарга юнәлтелә алмый.

**7 статья. Яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү**

Үзенә карата дәүләт ярдәме күрсәтелү турында карар кабул ителгән яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү граждан законнары нигезендә вәкаләтле оешма белән яшь гаилә арасында төзелгән торак бинаны сату-алу яисә алмаштыру шартнамәсе нигезендә башкарыла.

Торак бинаны сату-алу шартнамәсе сатып алына торган торак бина өчен 15 елдан да артык булмаган вакытта өлешләп түләү һәм сатып алына торган торак бина хакының кимендә 20 проценты күләмендә башлангыч кертем түләүнең мәҗбүрилеге шартларында төзелә. Торак бина өчен түләү буенча яшь гаиләгә өстенлекле ташламалар бирелгән өчен процентлар алынмый.

Түләүләрнең вакытлары, күләме һәм эзлеклелеге яшь гаиләнең керем дәрәҗәсен, закон нигезендә гаилә әгъзалары өчен билгеләнгән ташламаларны, төзелүче шартнамә нигезендә яшь гаиләнең заем акчаларын кайтару буенча үз йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү бирелешен исәпкә алып, торак бинаны сату-алу шартнамәсендә билгеләнә.

Яшь гаилә үзенең торак бинасын сатып алына торганына алмашып, алмаштыру шартнамәсе нигезендә дәүләт милкенә тапшырырга йөкләмә алган яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләгәндә,

бәяләрдәге аерманы яшь гаилә шартнамә нигезендә 15 елга кадәр вакыт эчендә өлешләп түли, түләү буенча процентлар исәпләнми.

Торак бинаны сату-алу яисә алмаштыру шартнамәсе буенча түләү акчалата һәм (яисә) яшь гаиләнең милек хокукында булган торак бинасы белән башкарыла.

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә, өч яшькә кадәрге баласы булган яшь гаилә гаризасы буенча, балага өч яшь тулганчы түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш.

8 статья. **Яшь гаиләнең торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүен тәэмин итү**

Яшь гаиләнең торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүен тәэмин итү вәкаләтле дәүләт органы белән яшь гаилә арасында граждан законнары нигезендә төзелүче шартнамә нигезендә башкарыла, анда яшь гаиләгә торак бинаны төзүне һәм (яисә) реконструкцияләп бетерү өчен кирәк булган товарларны сату, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү каралырга мөмкин.

Торак бинаны төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерү турында шартнамә сатып алынучы товарлар, башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр өчен 15 елдан да артык булмаган вакытта өлешләп түләү һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр хакының кимендә 20 проценты күләмендә башлангыч кертемнең мәҗбүрилеге шартларында төзелә. Сатып алынучы товарлар, башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр өчен түләү буенча яшь гаиләгә өстенлекле ташламалар бирелгән өчен процентлар алынмый.

Төзелә торган шартнамә буенча түләүләрнең вакытлары, күләме, эзлеклелеге анда яшь гаиләнең керем дәрәҗәсен, законнар нигезендә аның әгъзалары өчен һәм төзелә торган шартнамә нигезендә яшь гаиләнең үз йөкләмәләрен үтәвен тәэмин итү өчен бирелүче ташламалар булуын исәпкә алып билгеләнә.

9 статья. **Йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү**

Әлеге Закон нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәү граждан законнары нигезендә тәэмин ителә.

10 статья. **Дәүләт ярдәмен финанслау**

Дәүләт ярдәмен финанслау чираттагы финанс елына тиешле бюджетларны раслаганда Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар исәбеннән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм халык депутатларының җирле Советлары билгели торган күләмнәрдә башкарыла. Дәүләт ярдәмен финанслау өчен законнарда тыелмаган башка чыганаклардан да акчалар җәлеп ителергә мөмкин.

Дәүләт ярдәмен күрсәтү өчен бүлеп бирелгән финанс чараларын юнәлтү әлеге Закон нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтү чараларының дәүләт заказчысы булган вәкаләтле дәүләт органы белән район, шәһәр яисә шәһәрдәге район җирле администрациясе арасында Татарстан

Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслаучы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төзелүче шартнамә нигезендә, бары тик максатчыл билгеләнеше буенча гына башкарыла.

Яшь гаиләләр белән әлеге Закон нигезендә төзелә торган шартнамә шартлары нигезендә кире кайтарылган финанс чаралары дәүләт ярдәмен күрсәтүне дәвам итү өчен вәкаләтле дәүләт органына керә яисә, яшь гаиләләргә дәүләт ярдәмен күрсәтү ихтыяҗы булмаган очракта, тиешле бюджетларга җибәрелә.

Вәкаләтле дәүләт органы дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бүлеп бирелүче акчаларның максатчыл кулланылышы өчен җаваплы була.

11 статья. **Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр**

Яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту түбәндәге очракларда булырга мөмкин:

яшь гаилә биргән документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән белешмәләр булганда;

әлеге Законның 4 статьясында каралган нигезләр булмаганда.

Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту турындагы карар район, шәһәр һәм шәһәрдәге район җирле администрациясенең баш тарту нигезләре күрсәтелгән тәкъдиме буенча вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан кабул ителә. Карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә вәкаләтле дәүләт органы әлеге карар турында яшь гаиләгә хәбәр итә.

12 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

Әлеге Закон рәсми рәвештә матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әлеге Закон рәсми рәвештә матбугатта басылып чыккан көннән соң өч ай эчендә:

– норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга;

– әлеге Законы гамәлгә ашыру өчен кирәк булган норматив хокукый актларны әзерләргә һәм кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2443

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 740. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясенең түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы Президентының 2000 елга бюджет юлламасы турында.

2. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

3. «Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

4. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

5. «Төсле металл ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

6. «Тузган торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр, пикетлар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. «Акцизлар турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасының мировой судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

10. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законына өстәмә кертү турында Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12.«Коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Мактаулы ана» Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

15. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет

системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16.«2000-2005 елларда йогышлы авыруларны вакцина прафилактикасы» республика максатчыл программасы хакында.

17. «Татарстан Республикасы Югары суды Рәисен, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең беренче урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзаларын раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

18. «Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясын сайлау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

19.«Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының һәм аның аппараты хезмәткәрләренең эш урынындагы окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.

21. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.

22. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2416

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 741. Татарстан Республикасы Югары суды Рәисен, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең беренче урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзаларын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Баранов Геннадий Михайловичны Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе итеп сайларга һәм аны Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы рәисе итеп расларга;

Мәүлетшин Минзөфәр Мәүлет улын Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең беренче урынбасары итеп сайларга һәм аны Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзасы итеп расларга;

Шәрифуллин Риф Камил улын Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе урынбасары итеп сайларга һәм аны Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзасы итеп расларга;

түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Югары суды судьялары итеп сайларга:

Габдуллин Рәис Габделхак улын,
Ананьев Виктор Егоровичны,
Бегишев Олег Азизовичны,
Вәлиев Фидаил Рафаил улын,
Галимуллин Илгиз Сәмыйк улын,
Камалов Мансур Хәмит улын,
Кошелев Александр Ефимовичны һәм аны Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзасы итеп расларга,
Крупина Галина Ивановнаны,
Мәхмүтова Гөлүсә Мингази кызын,
Романов Лев Викторовичны һәм аны Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзасы итеп расларга,
Сафиуллина Нурия Галимҗан кызын,
Сухов Василий Ивановичны,
Сычев Аркадий Ильичны,
Хәмзина Лилия Фәрит кызын,
Харьков Анатолий Петровичны,
Шакирьянов Рафаил Вәли улын,
Шәкүров Булат Вакыйф улын һәм аны Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзасы итеп расларга,
Яхин Наил Фәрит улын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2417

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 742. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы

нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Хомяков Эдуард Геннадьевичны Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясы итеп сайларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2418

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 743.«2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 16 ноябре 16 сәгать 30 минутка кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бирергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2419

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 744. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проектын, мөмкин булган эчке хокукый каршылыкларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен, Татарстан Республикасы Конституциясенә тәңгәллеген билгеләү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2420

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 745. «Искергән торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы халык депутаты Т.М.Абдуллин мөрәҗәгатен һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясе карарын исәпкә алып Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 1999 елның 21 июлендә беренче укылышта кабул ителгән «Искергән торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2421

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 746. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 24 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 30 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2422

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 747. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе белән бергәләп «Коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы законы проекты концепциясен эшләүне дәвам итәргә һәм 2000 елның беренче кварталында карауны дәвам итү өчен аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2430

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 748. «2000-2005 елларда йогышлы авыруларны вакцина ярдәмендә профилактикалау» республика максатчыл программасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «2000-2005 елларда йогышлы авыруларны вакцина

ярдәмендә профилактикалау» республика максатчыл программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты чираттагы финанс елына һәм 2005 елга кадәр аннан соңгы елларга Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә әлеге программаны финанслауны аерым юл итеп карарга тиеш.

3. «2000-2005 елларда йогышлы авыруларны вакцина ярдәмендә профилактикалау» республика максатчыл программасының үтәлешен тикшереп торуны һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2431

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 749. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының эш урынындагы окладлары күләмен арттыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1999 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының эш урынындагы окладлары күләмен 1,5 тапкыр арттырырга һәм аларны кушымта нигезендә билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү фондын арттыру һәм чыгымнарны финанслау чыганаклары турында тәкъдимнәр кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2432

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 750. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенең 1995 елның мартыннан алып 1999 елның октябрендә кадәр чордагы эше турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм

милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе Р.М.Миңнуллинның 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чорда Комиссия эше турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе Р.М.Миңнуллинның 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чорда Комиссия эше турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2433

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 751. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы бәйләнеш мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турындагы хисап хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы бәйләнеш мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турындагы хисапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2434

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 752. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибенә түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. «И.Г.Тарханов кандидатурасын Татарстан Республикасының

мәдәният министры урынына килештерү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2435

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 753. И.Г.Тарханов кандидатурасын Татарстан Республикасының мәдәният министры урынына килештерү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 һәм 111 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Президентының Илдус Габдрахман улы Тархановны Татарстан Республикасының мәдәният министры урынына билгеләү һәм Марсель Мәзгар улы Таишевны, башка эшкә күчерелүе сәбәпле, бу урыннан азат итү турындагы тәкъдиме белән килешергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2436

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 754. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты проекты буенча җыелма бәяләмәсе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты проекты буенча җыелма бәяләмәсен игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы дәими комиссияләре бәяләмәсен, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советының XXI пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын карарга һәм аны үтәү барышында кирәкле аныклаулар кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2437

# II

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 755. Татарстан Республикасы Президентының 2000 елга бюджет юлламасы буенча парламент тыңлаулары уздыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Президентының 2000 елга бюджет юлламасы буенча 1999 елның 10 ноябрендә 14 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышлары залында парламент тыңлаулары уздыруны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 ноябре
№ 2401

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 756. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен чакыру вакытын үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 14 октябрендәге "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен чакыру турында"гы карарын үзгәртеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен 1999 елның 16 ноябрендә Казан шәһәрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 ноябре
№ 2403

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 757. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
2. "Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
3. "Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. "Акцизлар турында" Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. "1999 елда Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.
8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы элемтәләр мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турында хисабы
9. "Татарстан Республикасы Югары суды Рәисен, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең беренче урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең урынбасарын, Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасы Югары суды Президиумы әгъзаларын раслау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.
10. "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясын сайлау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

11. "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының һәм аның аппараты хезмәткәрләренең эш урынындагы окладларын арттыру турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 10 ноябре
№ 2404

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 758. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасы Президентының 2000 елга бюджет юлламасы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

2. "Төсле металл ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

3. "Тузган торакны бетерү өчен максатчыл салым турында" Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

4. "Митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр, пикетлар оештыру һәм уздыру тәртибе турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

5. "Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

6. "Коррупциягә каршы көрәш турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

7. "1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законына өстәмә кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

8. "2000-2005 елларга йогышлы авыруларны вакцина белән профилактикалау" республика максатчыл программасы хакында.

9. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,94

статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

10. "Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

11. "Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә берләшкән салым турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

12. "Акцизлар турында" Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне итү турында.

13. "1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

14. "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.

16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның октябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 ноябре
№ 2405

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 759. "Татарстан Республикасының үсеш бюджеты турында" һәм "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законнары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең бәяләмәсен исәпкә алып, "Татарстан Республикасының үсеш бюджеты турында" һәм "Татарстан Республикасында инвестиция

эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законнары проектларын эшләп бетерү өчен кайтарып бирергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елнын 10 ноябре
№ 2409

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 760. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясе чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясе чираттагы утырышын 1999 елның 1 декабрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елнын 22 ноябре
№ 2444

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 761. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе эшен дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе эшен 1999 елның 6 декабрендә Казан шәһәрендә дәвам итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елнын 22 ноябре
№ 2445

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 762. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аларның урындагы затларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

2. "Татарстан Республикасы халык депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

3. 1995 елның мартыннан алып 1999 елның декабренә кадәрге чорда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эшчәнлеге турында мәгълүмат.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 22 ноябре
№ 2446

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 763. 1999 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

2. "Хокук тәртибен тәэмин итүдә Татарстан Республикасы гражданнарының катнашуы турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

3. "Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә һәм аларны куллануга бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

4. "Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

5. "Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

6. "Халыкның санитар-эпидемия иминлеге турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

7. "Халыкны туберкулездан яклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. "Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка салу турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

9. "Гадәттән тыш хәлләрдә иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10."Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен сату-алу турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында" Федераль законның 24 статьясына өстәмә кертү хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

12. "Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында" Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 18 маендагы 1858-XII номерлы карарына үзгәреш кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

13. "Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлеше үтәлеше турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карарын үтәүнең барышы хакында.

14. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасының Ветераннар эшләре буенча комитетының, Мәскәү өлкәсе хезмәт ветераннарының, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органнары ветераннарының район җәмәгать оешмаларының Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару һәм башкарма хакимиятләре органнары җитәкчеләренә Россия Федерациясе ветераннарын хокукый һәм социаль яклауга карата дәүләт сәясәтен булдыру турындагы мөрәҗәгате хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

15. "Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртипкә салу чаралары турында" Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 нче карары хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 22 ноябре
№ 2448

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 764. 1999 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектларын кертергә:

1. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

2. "Халыкны туберкулездан яклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

3. "Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка салу турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

4. "Гадәттән тыш хәлләрдә иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

5 ."Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен сату-алу турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

6. "Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлеше үтәлеше турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карарын үтәүнең барышы хакында.

7. "Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртипкә салу чаралары турында" Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 нче карары хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 22 ноябре
№ 2449

## Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен